**Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы**
**Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәр Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 68-13 «14» декабрь 2021 ел

Җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен муниципаль район җирле үзидарә органнарына тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Азнакай муниципаль районы Советының 2015 елның 29 августындагы 175-48 номерлы карары белән расланган, Азнакай муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм Азнакай муниципаль районының җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибе белән

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәр Советы карар **итте**:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль район Советына Азнакай муниципаль районы башкарма комитетына җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Азнакай шәһәре башкарма комитеты вәкаләтләрен Азнакай муниципаль районы башкарма комитетына тапшыру мәсьәләсен карарга тәкъдим итәргә:

**Торак мөнәсәбәтләре өлкәсендә:**

- торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую һәм мәҗбүри күченүчеләргә торак сатып алу өчен субсидияләр бүлеп бирүгә Дәүләт торак сертификаты бирү;

- Чернобыль АЭСында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарга һәм «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авариягә дучар булган

гражданнарга һәм аларга тиңләштерелгән затларга Дәүләт торак сертификатын исәпкә алу һәм бирү;

- «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү»подпрограммасы буенча торак сатып алу (төзү) өчен социаль түләү алу хокукы турында таныклыкны исәпкә алу һәм бирү;

- социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу.

**Ваклап сату базары эшчәнлеге өлкәсендә:**

- ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү.

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М. З. Шәйдуллин